ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты эше турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты рәисе Д.Ф. Нургалиевның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты эше турындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты (алга таба – Яшьләр парламенты) эше турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына яшьләрнең хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы законнарны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә Яшьләр парламенты эшчәнлеген финанслауны оештыру буенча тәкъдимнәр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. 2025 елның 27 мартындагы 653-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә Яшьләр парламенты эшчәнлеген оештыруга акчалар бүлеп бирү буенча чаралар күрүне.

4.2. 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетында Яшьләр парламенты эшчәнлеген ел саен финанслауга акчалар каралуны.

5. Республика башкарма хакимият органнарына Яшьләр парламенты инициативаларына ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

6. Яшьләр парламентына:

6.1. Тәҗрибә алмашу максатларында Россия Федерациясе субъектлары закон чыгару органнары каршындагы яшьләр парламентлары (палаталары) белән регионнарара хезмәттәшлек буенча эшчәнлекне көчәйтергә.

6.2. Яшьләр белән традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне һәм гаилә кыйммәтләрен саклап калуга һәм ныгытуга, яшь гаиләнең уңай образын формалаштыруга, шулай ук туучылар санын арттыру өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән эшләрнең яңа рәвешләрен гамәлгә кертү мәсьәләсен карарга.

6.3. Кешенең һәм гражданның конституциячел хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын аңлы рәвештә төшенүне, сәяси грамоталылыкны һәм милли толерантлыкны үстерү максатларында яшьләрне хокукый тәрбияләү эшен көчәйтергә.

6.4. Ватанны саклаучылар елын уздыру кысаларында Яшьләр парламенты планын гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә.

6.5. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга гуманитар ярдәм җыю һәм җибәрү, аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү эшен дәвам итәргә.

6.6. Луганск Халык Республикасы Халык Советы каршындагы Яшьләр парламенты һәм шефлыкка алынган Лисичанск, Рубежное шәһәрләре территорияләрендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы социаль учреждениеләр белән, андагы халыкка кирәкле ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен оператив хәл итү максатларында, хезмәттәшлекне көчәйтергә.

7. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары каршындагы яшьләр советларының үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 9 октябре
№ 119-VII ДСП